ЗАМАНЧА БУЛСЫН

Хатын-кызлар авылларда банкомат куюны сорый

> 2

ЧЕМПИОН БИЛГЕЛЕ

Авыл хуҗалыгы министрлыгында республика бәйгеләре җиңүчеләрен бүләкләделәр

> 2

СУД ЗАЛЫННАН

Мираска хуҗа булу өчен улы әтисен үтерә

> 3

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 181 (28763) | Шимбә | 11 декабрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

QR-КОДЫҢ БАРМЫ, КЫШ БАБАЙ?

САГЫНЫП КӨТКӘН КУНАК ТА БЫЕЛ ПРИВИВКА ЯСАТКАН ОЧРАКТА ГЫНА КИЛӘ АЛАЧАК

Сабыйларны сөендерәм, дисәң, башта QR-кодыңны күрсәт! Яңа елда бәйрәм кәефе өстәүче Кыш бабайларга быел әнә шундый җитди таләп куелган. Сабыйларны сөендерергә җыенган аксакалның капчыгында хәзер бүләктән тыш, битлек, пирчәткә, антисептик һәм коронавируска каршы ике вакцинаны да ясатканлыгын дәлилләүче QR-коды да булырга тиеш.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кыш бабайны әбиләр дә көтә

Берничә көн элек Россия Дәүләт Думасы депутаты Виталий Милонов, балалар янына QR-коды булган Кыш бабай гына килергә тиеш, дигән тәкъдим белән чыкты. Депутат фикеренчә, прививка ясатмаган аксакал ковид инфекциясен ике тапкыр күбрәк таратырга мөмкин. «Мондый эш белән вакцинасыз шөгыльләнергә ярамый. Бу эшчәнлекне дә күпмедер дәрәҗәдә кысага кертеп, контрольгә алыр чак җитте», – дип саный депутат.

Дөрес, быел Яңа ел бәйрәмендә QR-кодлы Кыш бабайларның гына эшли алачагын Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе алдан ук кисәткән иде. Идарә вәкилләре бәйрәм чараларында эшләүче Кыш бабай һәм Кар кызларының әнә шул документын тикшереп, махсус рейдлар да үткәрергә җыена. Шәхси игълан буенча чакырылган кунакларның QR-кодын заказ бирүчеләрнең үзләренә тикшерергә кушалар. «Бер генә ата-ана да баласының, гаиләсенең шул рәвешле коронавирус йоктырып, бәйрәм кәефе бозылуын теләмидер», – диелә ведомство хәбәрендә.

Озак еллардан бирле Кыш бабай булып эшләүче журналист Нияз Рахман бу яңалыкны тыныч кабул иткән. «Җәмгыятьтә шундый таләп бар икән, ул Кыш бабайларга да кагылырга тиеш. Син бит аерым бер гаилә яшәгән йортка, балалар бакчасына, ниндидер оешма уздырган корпоративка QR-код белән барып, андагы кешеләрнең бәйрәм кәефен генә түгел, аларның сәламәтлеген дә кайгыртасың», – ди ул. Ул коронавируска каршы прививканы вакцина белән бәйле ыгы-зыгылар башланганчы ук ясатып куйган. QR-коды – кулында. Заказ алынган җиргә барыр алдыннан иң элек йортта, оешмада вирус белән авыручылар бармы-юкмы икәнлекне сораша. Узган ел билгеләнгән көнне балалары авырып киткәч, кайбер гаиләләрне гыйнвар уртасында котлап китәргә дә туры килгән.

Нияз Рахман сүзләренә караганда, быел өйгә килеп, Яңа ел белән котлауны сораучылар шактый кимегән. Андыйлар узган ел да аз булган. «Әле халык уянып кына килә. Бәйрәм исе яңарак кына килә башлады бит. Ай азагына кадәр, бәлки, өйгә чакырулар да күп булыр. Балалар бакчасыннан килегез дип шалтыратучылар булды. Корпоративларга, ишегалды бәйрәмнәренә дә шактый чакырулар килде», – ди Нияз. Иң кызыгы: соңгы елларда балачакта Кыш бабай белән очрашу турында хыялланып та, аның белән күрешә алмаган әбисен, тормыш иптәшен килеп котлап китүне сорап шалтыратучылар да очрый башлаган.

Быел чынын күрәсе килә

Бөтен җирдә бәйрәм мохите хөкем сөргәндә бернинди чир, проблемалар турында да уйлыйсы килми шул. Иске елны күтәренке кәеф, якты уйлар белән генә озатасы килә. Адәм баласының бу теләгенең ни дәрәҗәдә көчле икәнен рәсми саннар да раслый. «Авито. Хезмәтләр» сервисыннан алынган мәгълүматларга караганда, бер ел эчендә Татарстанда бәйрәмгә Кыш бабай һәм Кар кызын чакырулар 1,5 тапкыр арткан. Казанда аниматорларга ихтыяҗ, узган елның шушы чоры белән чагыштырганда, 70 процентка арткан.

«Узган ел ата-ана баласына, якыннарына чир йоктырудан куркып, Кыш бабайдан видеокотлау яздыру белән генә чикләнсә, быел күпләр Кыш бабай һәм Кар кызын өенә чакырырга тели», – диелә тикшеренүдә. Былтыр, коронавирус аркасында кертелгән чикләүләр нәтиҗәсендә, республикадагы ата-аналарның нибары 11 проценты гына Яңа елда аниматорларга мөрәҗәгать иткән. Гаиләләрнең 26 процентында балаларны Кыш бабай белән Кар кызы булып киенеп кергән туганнары котлаган.

Бәйрәмнәр оештыру белән шөгыльләнүче агентлык җитәкчесе Ольга Штольц сүзләренә караганда, быел шактый җанлану сизелә. «Яңа ел бәйрәмнәре оештыру өчен берничә сәгатьлек кенә буш вакытыбыз калды. Моңа бик шатландык. Узган ел заказлар бик аз булган иде. QR-кодларга килгәндә, без оештырган чараларда эшләгән барлык аниматорлардан шушы документны таләп итәчәкбез», – ди җитәкче.

Һәрчак аек һәм прививкалы

Бәйрәм көннәрендә эшләүче Кыш бабайлар бу яңалыкны эләктереп алган инде. «Авито» сайтындагы һәр мондый төр игълан «QR-кодым бар», «ике прививканы да ясаттым» ише сүзләр белән тәмамлана. Бер Кыш бабай барыннан да уздырырга теләп булса кирәк: «Мин һәрчак аек һәм прививкалы», – дип язып куйган.

Ахыры 2 нче биттә >

Киеренке атна

Татарстанда җәмәгать транспортында йөрү өчен QR-код системасы кертелгәннән соң, пассажирлар саны 23 процентка кимеде. Транспорт йөртүчеләр өчен дә, пассажирлар өчен дә киеренке атна артта калды – пассажирлар агымы акрынлап элеккеге күрсәткечләренә кайта. Хәзер бу күрсәткеч 13 процентка калган. Бу хакта Татарстанның транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары вазыйфаларын башкаручы Алексей Сидоров белдерде.

Министрлык вәкиле QR-кодлар тикшерүдә берникадәр «йомшару» сәбәпләрен дә аңлатты. «Бу – кеше факторы. Һәр кондукторга күзәтүче беркетеп булмый. Автобус йөртүчеләренә ярдәм итү өчен мобиль төркемнәр оештырылды. Җәмәгать транспортында йөрүче кеше буларак әйтәм – минем QR-кодны тикшерми калганнары юк», – диде Алексей Сидоров.

Аның сүзләренчә, транспорт йөртүчеләр өчен билгеле бер кыенлыклар саклана. Пассажирлардан тискәре фикерләр ишетү, QR-код мәсьәләсендә мәгълүмат җитмәүдән зарлар күп булган. 60 яшьтән өлкәнрәкләр исә транспорт карталарыннан файдаланып булмаудан зарланган. Билгеле булганча, вакцина ясатмаган яисә коронавирус белән авыру турында белешмәсе булмаганнарның транспорт картасын гамәлдән чыгарганнар иде. Хәзерге вакытта 607 кеше вакытлыча үз картасыннан файдалана алмый.

Җәмәгать транспортындагы вазгыять республика хакимиятенең контролендә.

Кәгазь акча кими

Быел гыйнвар – сентябрь айларында Татарстанда яшәүчеләр банк карталары белән барлыгы 457,7 миллиард сумлык товарга һәм хезмәтләргә түләгән. Бу – алдагы елдагы белән чагыштырганда 13,2 процентка күбрәк. Гомумән алганда, электрон акча белән исәп-хисап күләме 20,5 процентка артып, 658,6 миллион сумга җиткән. Республикада 9 ай эчендә товарларга һәм хезмәтләргә банк картасы белән түләү күләме терминалдан алынган «тере» акча күләменә караганда 15 тапкыр күбрәк булган. Банк картасы белән түләүнең уртача күләме – 695 сум, «тере» акчага алу күләме 12,8 мең сум тәшкил иткән.

Республикада электрон түләү инфраструктурасын үстерү дәвам итә. 1 октябрьгә сәүдә һәм хезмәтләр күрсәтү оешмаларында 93 мең электрон терминал урнаштырылган. Бу – 2020 елдагыга караганда 4 процентка артыграк.

Орлык әзерләү тәмамланган

Татарстанда «Экология» илкүләм проекты буенча урманнарның төп агачлары орлыкларын әзерләү эше төгәлләнгән. Урман хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматларына караганда, быел барлыгы 40,2 мең кг орлык җыелган. Шуның 395 килограммы – нарат, 207 кг – чыршы, 38 кг – карагай, 1,1 мең кг – каен, 40 кг – юкә, 790 кг – корычагач, 37,6 мең кг – имән орлыгы. Бу эш урман биләмәләрендә, шулай ук махсус биләмәләрдә башкарылган. «Урманда агач орлыкларын җыю «Татарстан Республикасында урманнарны саклау» төбәк проектының өстәмә күрсәткече булып тора. Быел билгеләнгән планны күпкә арттырып, 251 процентка үтәдек. Имән һәм каен уңышы әйбәт булу нәтиҗәсендә шуның кадәр күп орлык җыюга ирешелде. Барлык орлыкларга, Татарстан Урманнарны саклау үзәгендә тикшерү узгач, сыйфат сертификатлары бирелде», – ди урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров.

Гаебен таныган

Май аенда Казанның 175 нче гимназиясендә балаларга аткан Илназ Галәвиевкә ахыр гаепләү белдерелде. Бу хакта Россия Тикшерү комитеты сайтында хәбәр ителә. Галәвиев берьюлы дүрт – «Ике һәм аннан күбрәк кешене үтерү», «Җәмгыять өчен куркыныч ысул белән ике һәм аннан күбрәк кешене үтермәкче булу», «Шартлаткыч матдәләр, шартлаткыч җайланма әзерләү һәм саклау», «Читләрнең милкен белә торып юкка чыгару һәм зыян салу» статьялары буенча гаепләнә.

Моннан тыш Галәвиев үз акылында дип танылган. Ул үз гаебен тулысынча таныган һәм кылган гамәлләренә үкенүен белдергән. Җинаять эше буенча 600 кеше зыян күргән дип санала. Тикшерүчеләр фикеренчә, ул интернетта куркыныч төркемнәр турында мәгълүмат табып, гимназиядә һөҗүм оештырганда аларны кабатларга омтылган. «Якын араларда зыян күрүчеләр, шуннан соң гаепләнелүче һәм аның адвокаты җинаять эше материаллары белән таныштырылачак», – диелә Тикшерү комитеты сайтында. Сүз уңаеннан, Галәвиев хәзер Казанда тикшерү изоляторында үзе генә тотыла. Ул тәүлек әйләнәсе күзәтеп торыла. Хәзер җинаять эшендәге материаллары белән зыян күрүчеләр һәм аларның законлы вәкилләре, аннары гаепләнүче үзе һәм аның адвокаты танышачак.

Вазгыять ни хәлдә?

Бәйрәмгә кадәр өлгерәсе

КҮМӘК ИММУНИТЕТ ӨЧЕН 300 МЕҢЛӘП КЕШЕНЕҢ ВАКЦИНА ЯСАТУЫ КИРӘК

Татарстанда коронавируска каршы күмәк иммунитет күрсәткече 72 процентны тәшкил итә. Яңа елга 80гә кадәр җитәргә ният бар. 300 меңләп кешенең вакцина ясатуы кирәк.

Гомумән алганда, республикадагы коронавируска бәйле вазгыять ни хәлдә? Чикләүле, QR-кодлы яшәешнең куандырырлык нәтиҗәләре бармы? Белгечләр шул хакта журналистларга сөйләде.

Татарстанда коронавирус белән чирләүчеләр саны кими бара. Узган тәүлектә 185 очрак теркәлгән. Коронавируска шик белән медицина күзәтүендә 13 меңнән артык кеше кала. 176 кеше савыккан.

– Без авыручыларның кимүенә бәйле аз гына үзгәреш барлыгын күзәтәбез. Авыручылар саны алдагы атнадан 8 процентка кимрәк, – диде Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе башлыгы урынбасары Любовь Авдонина.

Аның каравы ОРВИ һәм грипп белән хәлләр сөендерерлек түгел. Белгечләрне шул сагайта. Саннарга ышансаң, шушы ике чир белән авыручылар күрсәткече, узган атна белән чагыштырганда, 11 процентка күбрәк. Әле шушы арада гына 54 яңа очрак теркәлгән. Барлыгы республикада яшәүче 87 кеше авырый.

– Мөмкинлек барында гриппка каршы прививка кадатырга өндибез. Вакытында үзеңне кайгырту зарур. Вакциналар җитәрлек, – диде Любовь Авдонина бу җәһәттән.

Белгеч әйтүенчә, балалар өчен грипп коронавируска караганда куркынычрак. «Балалар арасында грипп белән авыручылар саны борчуга сала. Республикадагы балаларның 60 проценты прививка кадатты. Без бу эшне дәвам итәбез», – диде Роспотребнадзор вәкиле.

Яңадан коронавирус турында әйткәндә, хәлләрнең тотрыклануы тиз арада үзгәрергә дә мөмкин. Татарстанның Сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков әйтүенчә, кабат вакцина ясату (ревакцинация) булмаса, вазгыять ярты елда тискәре якка авышмагае. Ревакцинацияне Татарстанда яшәүчеләрнең 90 меңнән артыгы узган инде. Хәзерге вакытта коронавируска каршы вакцинаны 2189735 кеше ясаткан. 1855123 кеше икенче дозасын алган.

Мондый шартларда Яңа елны каршы алганда чикләүләрнең кимүен көтәргә мөмкинме? Белгечләр әлегә җавап бирергә ашыкмый. Любовь Авдонина аңлатканча, хәзер вазгыятьне өйрәнәләр. Шунысы бар: уңай үзгәрешләр сизелә. Вакцина ясатучылар саны арту хисабына санитар-эпидемиологик хәлнең тотрыклануы күренә. Бәлки әле Яңа ел төнендә кафе-рестораннарга төнге сәгатьләрдә эшләү мөмкинлеге бирмәгәйләре. Любовь Авдонина әйтүенчә, җәмәгать туклануы тармагына бәйле төгәл карар киләсе атнада кабул ителәчәк. «Ниндидер үзгәрешләр кертергә мөмкинлек юк. Бер атнадан, әгәр вазгыять тотрыклы булса, карар кабул итәчәкбез», – диде ул. Әйтүләренә караганда, карар кабул ителгән вакытта белгечләр коронавирус, грипп һәм ОРВИ белән авыру күрсәткечләренә таяначак.

Сүзгә-сүз

Татьяна МОСКАЛЬКОВА, Россиянең кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле:

Халык тормышның һәм сәламәтлекнең кадерен күбрәк белә башлады. Хроник авырулар вакытында планлы медицина ярдәме ала алмауга бәйле мөрәҗәгатьләр өч тапкыр диярлек артты. Дарулар белән тәэмин итүгә кагылышлы шикаятьләр дә күбәйде. Пандемиянең тагын бер нәтиҗәсе: үзизоляция үз йортыңның кадерен белергә өйрәтте.

(«Российская газета»дагы әңгәмәдән)

РОССИЯДӘ ЯШӘҮЧЕЛӘР 2022 ЕЛДАН НИ ӨМЕТ ИТӘ?

Яхшы хезмәт хакы, яңа эш урыны, һөнәри үсеш. SuperJob хезмәте Россия халкыннан 2022 елдан нәрсә өмет итүләре турында белешкән. Сораштыруда 1600 кеше катнашкан.

Хезмәт хакы артуы	55%
Эш урынында тотрыклылык	33%
Һөнәри үсеш	26%
Хезмәт шартларының үзгәрүе	16%
Үзгәрешләр көтелми	8%
Эшнең кимүе	6%

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Хокуклар көрәшеп туа

Дөнья җәмәгатьчелеге бу җомгада Халыкара кеше хокуклары көнен билгеләп үтте. 10 декабрьгә бәйләнешле әлеге глобаль дата 1948 елда БМО кабул иткән үтә дә әһәмиятле документка – Кеше хокуклары декларациясенә барып тоташа.

Декларация «Бөтен кеше дә дөньяга ирекле, башкалар белән тигез хокуклы булып туа» дип башлана һәм җәмгысы 30 маддәдән торган текстта һәр территориядә, дәүләттә үтәлергә тиешле нормаларны тәфсилләп санап чыга. Яшәүгә, хезмәткә, белемгә, социаль яклауга, ялга хокук. Фикер, мәгълүмат иреге, дин иреге, башкалар…

БМО үзе 1945 елда – кешелек кичергән иң канкойгыч, иң җимергеч сугыш бетүгә үк Җир шарында бүтән андый гарасатны булдырмау, куркынычсызлык тәэмин итү максатыннан яралса, Декларация өстендә эш тә, язуларынча, шул елны ук башлана. Әйтергә кирәк, әлеге документ – БМОның бик үк озын булмаган тарихында кабул ителгән төп карарларның берсе. Бүген Декларациянең күпчелек маддәләре дөнья илләренең Төп Законнарында урын алган һәм хәтсез дәүләтләрдә алар үтәлеп тә килә. Ләкин, ни кызганыч, үтәлмәгән яисә ярты-йорты гына үтәлгән тарафлар да юк түгел. Бу хәл үз чиратында җәберләү, кыерсытылуларның дәвам итүе, авторитарлык һәм дә тоталитарлык, ахыр чиктә, яңа сугыш куркынычы, дисәк тә хата булмас.

Без яшәгән ил – Россиягә килгәндә, аның Конституциясендәге 48 маддәдән (17–64 маддәләр) торган икенче бүлек тулысы белән кеше һәм гражданинның хокук һәм ирекләренә багышланган. 1993 елда – демократик үзгәрешләр чорында кабул ителгән Төп Законның ул бүлеге 2020 елгы конституцион реформадан соң да үзгәрешсез калды. Бу, әлбәттә, сөенечле хәл. Үз эченә 137 маддә сыйдырган Конституциябезнең өчтән береннән артыгы хокуклар хакында икән, илебез дә тиешле дәрәҗәдә хокукый, ирек-хокуклар ягыннан башкаларга үрнәк дәүләт булырга тиеш кебек.

Хокук һәм ирекләр дигәндә, соңгы елларда безне – милли азчылыкларны иң нык борчыганы, әлбәттә, илнең федерация юлыннан тайпылып баруы аркасында килеп туган вазгыять. Гамәлдәге Төп Законда каралган хокукларның кайберләренә генә тукталып үтик. 26 нчы маддәнең 2 нче пунктында һәркем үз милли телендә белем алырга хокуклы диелгән. Шушы маддәнең үтәлмәвенә үртәлеп, без – татарлар тәмам хәлдән тайдык, дию генә аздыр. Гаҗизлек шунда: Мәскәү тарафларында, унитарлыкка алынган курс сәбәпле, безнең аргументларны ишетмиләр. Бу – милләт үз-үзен, аерым алганда, үз милли мәгарифен яклаудан мәхрүм дигән сүз.

Бу юлларның авторы «торгынлык» елларында рус теле һәм әдәбиятыннан кала бар фәннәрне татарча укып, барысы буенча да татарча имтихан биреп аттестат алган кеше. Баласын кызганып: «Вузларда барысы да русча, мәктәптә дә русча укысын», – дип кыбырсыган ата-аналарга искәртәсем килә: дәрәҗәле техник вузга кергәндә, укып киткәндә, русча терминология белән бәйле аз-маз кыенлыклар сизелсә дә, нинди дер олы, үтеп чыга алмаслык киртәләр тоймадым. Кыенлыклар якадан алса, икенче курстан югары стипендия алып булыр иде микән? Мәктәптә татарча гыйлем эстәгәнемә һичкайчан үкенмәдем генә түгел, татарлыкны, милли җанлылыкны саклауда төп роль уйнаган татар мәктәбенә мин гомерем буе рәхмәтле. Ә бүген нәрсә күрәбез? БДИ дип фәннәрне русча укыту нәтиҗәсендә, мәктәптә татар мохите сыегаеп бара, кысрыклана. Татар авылында татар балаларының үзара русча аралашуына үзем шаһит булып, ул хакта язган идем инде. Болай барса, моңарчы милләт инкубаторы булган татар авылы үз миссиясен бик тиздән үтәми башлаячак. Ата-аналар, агым уңаена йөзгәнче, хокуклар өчен, татарча БДИ өчен көрәшсә иде.

Яңадан кеше хокукларына кайтып, Төп Законның 29 нчы маддәсенә, аның 5 нче пунктына мөрәҗәгать итик. Анда акка кара белән илнең барлык гражданнарына мәгълүмат иреге гарантияләнә, цензура тыела, диелгән. Маддә үтәләме? Классигыбыз Мөхәммәт Мәһдиев, исән булса, бу урында «едва ли» дияр иде. Ә мәгълүмат ирексезлеге үзе артыннан башка төр ирексезлекләрне ияртә…

Гавамның да олы өлеше үз хокукларын белеп бетерми булыр. Хокуклар өчен көрәшү зарурлыгын да аңлап җиткерми. Яклау сорап каядыр, кемгәдер мөрәҗәгать итү турында әйткән дә юк. Халыкның ничә проценты Россиядә Кеше хокуклары советы (СПЧ) барлыгын, халыкара оешмалардан ЕСПЧ (кеше хокуклары буенча Европа суды) дигән мәхкәмә эшләп килгәнен белә икән? Ә бит дәүләт хокукый дәүләткә әйләнсен дигәндә беренче чиратта аның гражданнарының активлыгы, хокуклар өчен көрәшүе кирәк. Милләт хокуклылыгы да җитәкчелектән бигрәк, аерым кеше – милләт вәкиленең кыюлыгыннан һәм булдыклылыгыннан торадыр.

Кеше хокуклары көне белән!

10 декабрьдә Кеше хокуклары көне билгеләп үтелә. Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сәрия САБУРСКАЯ газетабыз аша котлау җиткерде.

– Кешелек дөньясы коронавирус инфекциясе таралу аркасында берни белән чагыштырып булмый торган гомумкешелек кризисын кичерә. Планетаның һәр кешесе өчен катлаулы бу чорда халыкара Кеше хокуклары көне тагын да зуррак әһәмияткә ия. Хәзер без барыбыз да төп хокукыбыз – тормышка хокук өчен көрәшәбез. Һәр кеше гомере өчен хәзер иң төп хокук сакчылары – табиблар һәм медицина хезмәткәрләре. Аларның хезмәте бәһаләп бетергесез, без аларга тырыш хезмәтләре өчен бик рәхмәтле, – диелә котлауда. – Замана шартларында элеккеге хокукый мөнәсәбәтләрне саклау, яңаларын булдыру, кеше хокукларын һәм ирекләрен саклау һәм яклауны тулы күләмдә дәвам итү кыен булуга карамастан, минем коллегаларым, кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр, аларның Аппарат хезмәткәрләре һәм җәмәгатьчелек ярдәмчеләре, хокук сакчылары, гражданлык җәмгыяте институтлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары моның өчен бар тырышлыгын куя.

Безнең уртак миссия – киләчәк буыннарда кеше хокуклары культурасын формалаштыру һәм тәрбияләү, барлык илләрдә ирек тантана итү, куркынычсызлыкны һәм тынычлыкны ныгыту өчен кулдан килгәнчә тырышу. Халыкара кеше хокукларын яклау көне мөһим гражданлык башлангычларын яклауга, законнарны ихтирам итүгә һәм саклауга, хокукый аң-белемне күтәрүгә, чын гражданлык һәм толерантлык күрсәтүгә булышлык итсен!

ЯШӘСӘК ТӘ ТӨРЛЕ ИЛЛӘРДӘ…

Кичә Казанда Татарстан Президенты каршындагы Ватандашлар эшләре буенча координация советы утырышы узды. Анда бу елдагы эшләргә йомгак ясалды. Утырышны Дәүләт Советы Рәисе, Координация Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин үткәрде.

– Ватандашлар белән уртак эшебез федераль хакимият органнары тарафыннан югары бәяләнде, – дип билгеләп үтте Фәрит Мөхәммәтшин, утырышны ачып. – Ватандашларның җиденче Бөтендөнья конгрессында республика делегациясенең катнашуы йомгаклары буенча Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов исеменә Россия тышкы эшләр министры Сергей Лавровтан эшебезгә рәхмәт белдерелгән хат алынды. Татарстан ватандашлар белән аеруча әйбәт эшләүче федерация субъектларыннан берсе буларак бәяләнде.

Фәрит Мөхәммәтшин, узып баручы елга йомгак ясап, мөһим вакыйгаларның берсенә – Бөтенроссия халык санын алуга аерым тукталып үтте. «Без үз телебезне, традицияләребезне, татар халкының гореф-гадәтләрен, санын саклау зарурилыгы буенча бурычлар куйдык, – диде парламент башлыгы. – Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты бу җәһәттән зур аңлату эше алып барды».

Фәрит Мөхәммәтшин быел республикада Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы игълан ителүнең зур әһәмияткә ия булуын искәртте. Төп чаралар планын тормышка ашыруга республиканың барлык хакимият органнары, Татарстан оешмалары һәм вәкиллекләре җәлеп ителде. Чаралар кысасында чит илләрдә яшәүче ватандашларыбыз, федерация субъектларындагы татар иҗтимагый оешмалар активы, шул исәптән онлайн режимда, катнашты.

Дөньядагы катлаулы вазгыять шартларында ватандашлар белән нәтиҗәле диалогны үстерергә кирәк, дигән фикердә парламент спикеры. Бу юнәлештә билгеле бер уңышларыбыз да бар. Шул ук вакытта Фәрит Мөхәммәтшин ватандашларның ихтыяри күченүенә ярдәм итү буенча республика дәүләт программасын тормышка ашыру барышына борчылуын белдереп үтте. Аерым алганда, быел бу максатка юнәлдерелгән федераль субсидияләрнең 50 проценттан кимрәге генә үзләштерелгән. Фәрит Мөхәммәтшин бу эшне көчәйтергә чакырды.

Быел мәгариф өлкәсендә ватандашлар белән эшләү йомгаклары турында мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин сөйләп үтте. Хәзерге вакытта Россиянең 28 субъектында татар теле өйрәтелә, якшәмбе мәктәпләре эшли. Бу мәгариф оешмаларында 1,1 меңнән артыграк татар теле һәм әдәбияты укытучысы хезмәт итә, диде ул. Министр әйтүенчә, «Ана теле» онлайн мәктәбендә 28 меңнән артыграк кеше теркәлгән. Шуның 1 меңнән артыграгы – чит илдә яшәүчеләр.

Ватандашлар белән мәдәни элемтә, элеккечә үк, актив төстә алып барыла. Быел гына да 450дән артыграк чара үткәрелгән. Быел Россиянең 56 төбәгендә һәм 33 илдә 386 Сабантуй үткәрү планлаштырылган. Әмма эпидемиологик вазгыятьнең авыр булуы сәбәпле, бары тик 119 Сабантуй гына үткәрелгән.

Быел Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров тәкъдиме белән Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында Татарстаннан читтә яшәүче ватандашлар белән сәүдә-икътисади өлкәдә хезмәттәшлек буенча эш төркеме булдырылган.

Сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Родион Карпов искәртеп үткәнчә, 2021 елда чит илләрдәге һәм Россия төбәкләрендәге партнерларыбыз белән икътисади чараларны тормышка ашыру буенча 30 килешү төзелгән.

ЗАМАНЫНА КҮРӘ ТАЛӘБЕ

Яшәеш

Авылда яшәүче эшмәкәр, үзмәшгуль хатын-кызларны ниләр борчый? «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы кабул итү бүлегендә «кайнар элемтә» буенча «Мәрхәмәт – Милосердие» хатын-кыз депутатлар берләшмәсе вәкилләре аларның сорауларына җавап бирде.

– Узган очрашуда килгән 15 сорауның 13ен шундук хәл итеп булды. Икесе катлаулырак булгач, аларны әлегә өйрәнәбез, – диде депутат Елена Кузьмичева. – Күп кенә авыл хатыннарының үз эшен башлыйсылары килә. Әмма төп эшләреннән дә китәргә теләмиләр. «Ике эш бер-берсенә комачау итмиме?» – дип тә сораучылар бар. Шулай ук үзләре җитештергән товарны урнаштыруда ярдәм итегез, диючеләр дә шактый. Аларның проблемаларын аңлар өчен, мондый аралашуларны ешрак оештырырга кирәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Туры элемтә» вакытында депутат Римма Ратниковага Чаллыдан мөрәҗәгать иттеләр. Марина исемле ханымның шәхси мәктәп ачасы килә. Тик эшне нидән башларга кирәклеген белми. Депутат аңа иң элек шәһәр белем бирү идарәсенә барырга киңәш итте. Әлеге мәсьәләне үз контроленә алды.

Лениногорскида яшәүче Әлфия ханымның үзе үстергән күркәне интернет аша сатасы килә. Ярминкәләргә бару яки берәр сәүдә ноктасында сату өчен бик күп документлар җыярга кирәк икән. Шуңа да ул үз продукциясен үзе сатмакчы. Аңа да бу эшне ничек эшлисен бәйнә-бәйнә аңлаттылар.

Сораулар арасында иң еш яңгыраганы авылларда буш торучы банкларны эшләтү һәм банкоматлар кирәклеге хакында иде. «Туры элемтә» вакытында гына да өч кеше банкомат куюларын сорады. Депутатлар юк дими. Алар халык сораган банкларга мөрәҗәгать итеп, бу мәсьәләне хәл итәрбез, дип ышандыра.

Сүз уңаеннан, Идел буе федераль округы закон чыгару җыеннарының хатын-кыз депутатлары авылда яшәүчеләр хакында сөйләштеләр. Утырышта Татарстан Дәүләт Советы депутаты Алсу Нәбиева республика тәҗрибәсе белән уртаклашты.

– Татарстанда 2 миллионнан артык хатын-кыз яши, шуларның 460 меңнән артыгы авыл җирендә гомер итә. Республикада, авыл хатын-кызларына ярдәм итү буенча федераль чаралардан тыш, республика һәм муниципаль дәрәҗәдә чаралар күрелә, – диде ул.

Алсу Нәбиева Татарстанда авыл җирендә даими яшәүче 25 яшькә кадәрге хатын-кызларга бала тапканда бер тапкыр бирелә торган акча (беренче бала туганда – 50000 сум, өченче бала туганда – 100000 сум) турында сөйләде. Әлеге ярдәмне алучыларның яшен 35 яшькә кадәр арттыруны сорап тәкъдимнәр килә икән.

– Татарстанда авылда яшәүче хатын-кызларны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт ярдәме күрсәтелә. Ул 65 юнәлеш буенча гамәлгә ашырыла. Аларның 29ы – федераль, 36сы республика бюджетыннан финанслана, – ди Алсу Нәбиева.

Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова, Татарстан тәҗрибәсен Дәүләт Думасының профиль комитетында карадык, ул хезмәттәшләрдә кызыксыну уятты, ди.

– 2022 елда авылларга дәүләт ярдәме буенча федераль бюджеттан өстәмә 4,6 млрд сум акча бүленәчәк, – ди Татьяна Ларионова. – Мине авылларның картаюы борчый. Авыл яшьләр яшәгәндә һәм эшләгәндә генә үсәчәк. Безгә иҗтимагый аграр берләшмәләр һәм башка структуралар аша авыл яшьләре белән хезмәттәшлекне көчәйтергә кирәк дип уйлыйм.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ КОНСТИТУЦИЯСЕ КӨНЕ БЕЛӘН!

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның Россия Федерациясе Конституциясе көне уңаеннан КОТЛАВЫ

Хөрмәтле татарстанлылар! Сезне чын күңелдән иң мөһим дәүләт бәйрәмнәренең берсе – Россия Федерациясе Конституциясе көне белән котлыйм.

Яңа демократик Россиянең төп кануны 1993 елның 12 декабрендә кабул ителде, һәм менә инде утыз елга якын аның төп өлешләре какшамас нигез булып тора. Граждан хокуклары һәм ирекләренең үзгәрмәс статусы, дәүләт бердәмлеген һәм территориаль бөтенлекне саклап калу, идеология төрлелеге, ирекле сайлаулар һәм күппартиялелек, киң социаль гарантияләр нәкъ менә шундыйлардан…

Барыбызның да хәтеребездә: хәзерге Россия Федерациясе Конституциясе үзенең тормыш юлын бик авыр тарихи чорда «ярып» барды. Үткән еллар иң югары юридик көчкә ия булган Төп Законның яхшы ниятләр декларациясе генә булмавына горурланырлык тагын бер ныклы дәлил икәнен күрсәтә. Ул – Россия җәмгыятенең төп кыйммәтләр буенча һәрьяклап үлчәнгән ризалык акты, моның шулай икәнен 2020 елның җәендә узган төзәтмәләр буенча Бөтенхалык тавыш бирү дә тагын бер мәртәбә раслады. Күпмилләтле дәүләтебезнең үсеш юнәлешен билгеләүче бу «тере», чын мәгънәсендә эшләүче документ булдыру һәм берләштерү эшчәнлегендә җитди роль уйнады. Социаль-сәяси тотрыклылыкка нигез салды, илебезнең дөньякүләм абруен ныгытуга ярдәм итте. Федерализм, ярдәмләшү принципларын Конституция белән беркетеп, барлык төбәкләрнең хокуклары тигезлеген тәэмин итте, аларга икътисадый үсеш юлларын иҗади һәм үз җаваплылыгында сайларга мөмкинлек бирде. Мондый алымның дөрес булуына үрнәк – безнең республика. Демократик яңарыш ярдәмендә без көчле норматив хокукый нигез булдырдык, сәнәгать сәясәтендә, социаль сәясәттә, рухи өлкәдә һәм халыкның муллыгын арттыруда күзгә күренерлек нәтиҗәләргә ирештек. Бүген Татарстан – Россиянең горурлыгы һәм терәге булган иң куәтле һәм динамик үсештәге төбәкләренең берсе.

Кадерле татарстанлылар! Һичшиксез, Ватаныбызны көчле һәм бай итәр өчен, әле бик күп хезмәт куярга кирәк. Ышанам ки, бу юлда Россия Федерациясе Конституциясенә хөрмәт һәм аның хокукый нормаларын тайпылышсыз үтәү уңышның мөһим өлеше булып тора. «Яратып башкарылмаган эшнең нәтиҗәсе дә булмас», диләр халыкта. Әйдәгез, Ватаныбыз алдындагы бурычыбызны үтәү һәм куелган максатларга тиз арада ирешү өчен, бер-беребезгә җаваплылык хисен тоеп эшләүне телик. Барыгызга да исәнлек-саулык, гаилә бәхете, имин һәм тыныч еллар телим!

QR-КОДЫҢ БАРМЫ, КЫШ БАБАЙ?

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Кыш бабай, Кар кызы котлавына ихтыяҗ арткач, хезмәтләре дә кыйммәтләнгән. Бер ел эчендә аларның котлау бәяләре 15 процентка үскән. Әйтик, узган ел Яңа ел чараларында аниматорларның бер сәгать эше 1 мең сумнан башланган булса, быел бәяләре якынча 2 мең сумнан башлана. Элегрәк уртача 2 мең сумга төшкән 15 минутлык экспресс котлау өчен быел 3 мең сум акчаңны чыгарып салырга туры киләчәк. 31 декабрь көнне исә Кыш бабайларның котлавы өч тапкыр кыйммәтләнергә мөмкин дип фаразлый белгечләр.

Дөрес, хәзерге вакытта игълан сайтларында 500 сумга гына Яңа ел белән котлап чыгарга вәгъдә иткән Кыш бабайларны да табарга була. Ләкин белгечләр андый аниматорларга сагаеп карарга киңәш итә. Ник дигәндә, андый чакта еш кына игъландагы фото буенча көтелгән бик купшы Кыш бабай урынына сәләмә киемле, зәгыйфь сакаллы, актерлык сәләте дә ташка үлчим булган «карт» килеп керергә мөмкин, ди алар. Роспотребнадзор белгечләре исә бу урында тагын бер мәсьәләгә игътибар итәргә куша. «Сезгә хезмәт күрсәтүче белән язмача килешү төзергә тырышыгыз. Ул ике нөсхәдә булсын. Килешүне имзалар алдыннан аны яхшылап укып чыгарга да онытмагыз. Акча түләвегезне раслаучы чекны да җыеп куегыз. Аниматор сезнең гаеп белән килешенгән хезмәтне күрсәтә алмаса, сез бу хезмәт өчен билгеләнгән сумманы тулысынча түләргә тиеш», – диелә идарә хәбәрендә.

Сүз уңаеннан, быел Татарстанда балалар бакчаларында узачак Яңа ел бәйрәмнәренә дә QR-коды булган ата-аналарны гына кертәчәкләр. «Белем бирү оешмаларында бәйрәмнәр бер төркем яки сыйныф кысасында гына уздырылачак. Бинага керүчеләрнең тән температурасы тикшерелә, антисептиклар куела, ике арада социаль дистанция сакланырга тиеш. Бирегә коронавируска каршы прививка ясаткан яки бу чир белән авырып терелгән ата-аналар гына кертелә», – дип ачыклык кертте журналистлар белән очрашуда Россия кулланучылар күзәтчелегенең Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КАМИЛЛЕКНЕҢ ЧИГЕ КҮРЕНМИ

Нәтиҗә

Берсе – чемпион, икенчесе – иң алдынгы. Спорт турында түгел сүз. Илмир Яруллин белән Айгөл Хәбриева Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы уздырган республика бәйгеләренең биш этабында да иң югары нәтиҗәләргә ирешеп зур җиңү яулады. 43 район белгечләре арасында берсе – нәсел эше операторы, икенчесе зоотехник-селекционер буларак иң югары нәтиҗәләргә иреште.

«Элита» нәсел хуҗалыгы баш зоотехнигы Фәнил Кәбиров әйтүенчә, конкурс шартлары буенча көрәшнең беренче этабы бәйгедә катнашучыларның теоретик белемнәрен тикшерүгә багышлана. Бу этапта һәр районның әйдәп баручы белгечләре дөньякүләм алдынгы тәҗрибәгә таянып, үз белемнәрен күрсәтә алды.

Пандемия аркасында онлайн форматта узган икенче этапта һәр белгеч үз осталыгын лаборатория шартларында сынап карый алган. Өченче этап терлекчелектә иң югары күрсәткечләргә ирешү юлларына багышланса, дүртенчесендә һәр белгечнең эш урынында булган җиһаз-җайланмаларны ни дәрәҗәдә нәтиҗәле куллануы ачыкланган.

– Конкурста катнашучылар арасында шушы биш этапта та җиңеп чыга алган бер белгеч республика конкурсында катнашу хокукына ия була алды. Иң-иңнәр Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында узган бәйгеләрдә ачыкланды, – диде Фәнил Кәбиров.

Татарстан Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров искәртүенчә, терлекчелек тармагында әйдәп баручы республикада мондый бәйгеләр элегрәк елларда да еш уздырылган. Быелгысының үзенчәлекләре дә бар. Конкурс беренче тапкыр башлыча онлайн форматта узган. Бәйгеләрдә терлекчелек тармагында иң югары нәтиҗәләргә ирешкән эре хуҗалыклар белән бергә фермер һәм шәхси хуҗалыгында күпләп мал-туар асраучылар да катнаша алган. «Иң алдынгы технологияләргә нигезләнеп эшләүче белгечләребезнең хезмәте киләчәктә дә игътибар үзәгендә булачак», – диде Марат Җәббаров, җиңүчеләргә истәлек медальләре һәм акча сертификатлары тапшырганда.

Конкурс нәтиҗәләреннән күренгәнчә, терлекчелек буенча иң алга киткән хуҗалыкларның төп сере үз эшен белеп, яратып эшләүче белгечләргә бәйле. Андыйлар Саба, Кукмара, Балтач, Әтнә, Мамадыш һәм кайбер башка районнарда күп. Шунысы сөенечле: бернинди кыенлыкларга карамый, терлекчеләребез ел саен югарырак нәтиҗәләргә ирешергә тырыша. Камиллекнең чиге юк дигән гыйбарә нәкъ менә шундый эш осталарына карата әйтеләдер.

Конкурста катнашучыларның һәркайсы махсус бүләкләр алды. Шуның өстенә ике конкурсның да абсолют чемпионы ачыкланды. Мөгезле эре терлек үрчетү операторлары 43 нче республика конкурсының абсолют чемпионы дип Мамадыш районы «Азык-төлек программасы» хуҗалыгыннан Илмир Яруллин, зоотехник-селекционерларның 43 нче республика конкурсы төп җиңүчесе дип Кукмара районы «Урал» хуҗалыгы зоотехник-селекционеры Айгөл Хәбриева танылды.

Камил СӘГЪДӘТШИН

«ЧИРАТЛАП УКЫЙБЫЗ, ЧИРАТЛАП БӘХӘСЛӘШӘБЕЗ»

Кукмара

Моннан берничә көн элек Кукмара Үзәк китапханәсендә «Ватаным Татарстан» газетасы журналистлары белән очрашу булды. Үткәннәр барланды, хәтер яңарды. Йөз елдан артык тарихы булган, төрле елларда төрле исем белән нәшер ителгән «Ватаным Татарстан» халкыбызның төп газетасы булды, шулай булып кала да, аның эшчәнлеге халкыбыз эшчәнлегеннән аерылгысыз.

Нинди генә катлаулы заманда да халык тормышның катлаулы сорауларына җавап эзләде, газета аша җавап тапты. Әлбәттә инде, халкыбызның төп газетасы һәм район газетасы һәр йортка диярлек килеп тора иде, газетасыз яшәүне күз алдына да китермәдек. Бу юлларны мин үзем дә барлык тормышымны газета эшчәнлегенә багышлаган кеше буларак язам һәм китапханәдәге очрашуда да газетаның әһәмияте турында дәлилле фикерләү булды, үткәнгә дә кайтып килдек, бүгенге үзенчәлекләрне дә онытмадык. Әмма басма матбугат юкка чыгар дигән фикер уебызга да керми, булмаячак та!

Ирле-хатынлы Рузалия, Илсур Гариповлар атнага дүрт тапкыр нәшер ителүче «Ватаным Татарстан»ны һәр көнне көтеп алулары һәм чиратлап укулары, аннан язмаларда күтәрелгән мәсьәләләр хакында фикер алышулары турында сөйләделәр. Бәхәсләшкән вакытлары да була икән, әмма ордым-бәрдем түгел, чиратлап, бер-берсен аңлап, үз итеп.

Очрашуда Миңнегөл Закирова күңелендәге хисләрне шигъри юллар аша да җиткерде. Кукмарабызның мөхтәрәм шәхесе, райондашларыбызны барлауда, тарихка кертүдә үзеннән зур өлеш керткән (Чыңгыз Айтматовның Кукмара төбәгендәге нәсел-нәсәбен барлау юнәлешендәге эшчәнлеге генә дә ни тора!) Ләбүдә Дәүләтшина үткәннәргә алып кайтты, матбугатның көндәлек тормыштагы әһәмияте турында үтемле итеп җиткерде.

Район мәдәният бүлеге мөдире Рамил Нуриевны тыңлаган саен тыңлыйсы гына килеп торды. Андагы тел байлыгы, хәтер-хатирәсе сокландыра, сөйләгәннәре бер сюжетка корылган, эчтәлекле. Мөгаен, киләчәктә газета укучылар да бу байлыкны үз итәр. Ул газета белән элемтәне ныгытырга вәгъдә бирде.

Очрашу, әлбәттә, теләк-фикерләр белән аралашып барды. Флера Әюпова, әйтик, сугыш чоры ятимнәрен сугыш чоры балалары белән бутамаска иде, дигән фикерен җиткерде. «Сугышка киткән менә без – биш бала ятим калдык. Ничек үскәнбез дә ничек тернәкләнгәнбез: сөйләп тә, язып та аңлатырлык түгел. Сугыш чоры ятимнәре онытылмаска тиеш», – ди ул.

Миңнегөл Закирова, Рәсимә Минһаҗева, Рәшит Миңнегалиев, Рафаэль Хәкимов һәм башкалар читтә гомер итүче милләттәшләребез турында киңрәк язуны сорады, элмә такталардагы хаталарның күңелне телгәләвенә, мәктәпләрдә татар теленең тиешенчә укытылмавына борчуларын белдерделәр. «Ватаным Татарстан» газетасына ташламалы язылу барган бу көннәрдә очрашуны оештырган район хакимиятенә, Равия Кәримуллинага, Резедә Касыймова җитәкчелегендәге Үзәк китапханә коллективына рәхмәтләрен җиткерделәр. Истәлеккә фотога да төштек.

Киңәшле эш таркалмый, ди безнең халык. Очрашу-киңәшләшүләрнең нәтиҗәсе дә бары тик уңай якка, файдага гына.

Габделбәр РИЗВАНОВ

Илдар Мөхәммәтҗанов

БЕЗНЕҢ ИЛСӨЯР

Хезмәттәш

Редакциябезнең баш хисапчысы Илсөяр Вәлиуллинаны без яратып, хөрмәт итеп, «безнең Илсөяр» дип йөртәбез. Бу сүз үзенә күрә ышаныч, сыйфат билгесе дә кебек. Безнең Илсөяр әйткән икән, димәк, шикләнергә урын юк. Ул уйламыйча, белмичә әйтмәс.

Илсөяр беркайчан, беркемгә дә тавыш күтәреп эндәшми. Сабыр гына соравыңа җавап бирә дә күзләреңә карый. Әле ике минут элек кенә күңелеңдә дулаган чарасызлык, билгесезлек, диңгез ярына килеп бәрелгән дулкын кебек, аның ышанычлы, сабыр күз карашында таралып юкка чыга. Илсөярдәге сабырлык әллә нинди ялкыннарны сүндерерлек кебек.

Әтисе Илфруз белән әнисе Альбирага дүрт кыз алар. Нәкъ әкияттәгечә берсеннән-берсе чибәр, акыллы булып үсәләр кызлар. Дүртесенең дә урта мәктәпне медальгә тәмамлауларын гына әйтсәк тә, кызларның нинди тырыш икәнлеген аңларга буладыр. Илсөяр – иң олысы. Китап укырга бик ярата торган әтисе кызына исемне Гариф Гобәйнең «Маякчы кызы» әсәрен укыганнан соң сайлый. Укырга өйрәнүгә, Илсөяргә дә китапны укып чыгарга тәкъдим итә.

Илсөяр балалар бакчасына йөрми, дәү әнисе тәрбиясендә үсә. Дәү әнисе дә укырга бик ярата, 87 яшенә кадәр газета-журналлардан аерылмый. Оныгы Илсөярне дә биш яшьтә «Социалистик Татарстан» газетасыннан хәрефләр күрсәтеп укырга өйрәтә. Алты яшендә инде Илсөяребез әбисе белән кунакка барган җиреннән, Ташкенттан, конверт тышына үзе язып, авылга әниләренә хат сала.

Кешенең гомер йомгагын сүтә башлыйсың да хәйран каласың. Ерак балачакта булган нәни генә күренешләр, үз чорында гади генә кебек тоелган вакыйгалар, еллар үткәч, кешенең гомер юлында янәдән бер чагылыш табар, үзенә күрә бер маяк булыр дип кем уйлаган?! Тормыш фәлсәфәсен тирәнтенрәк карасаң, бернәрсәнең дә очраклы түгел икәнлеген аңлыйсың. Тормыш дисбесен өзми алып барырга гына кирәк.

Илсөяр дә чут төймәләрен көйле генә тарткан кебек, тормыш дисбесенең дә рәтен чуалтмый җыйнап килә. Мәктәпне бетергәч, икътисадчы һөнәрен ала. Институтны тәмамлап, бер ел эшләгәч, авылдашы Нияз белән гаилә коралар. Ул һәм кыз тәрбияләп үстерәләр. Уллары инде гаиләле. Кызлары – булачак архитектор. Нияз – тәҗрибәле, хөрмәтле хирург. Коронавирус афәте башланганнан бирле «кызыл зона»да эшли. Хисапчы булмаса, Илсөяр үзе дә бик яхшы табиб булыр иде шикелле. Медицина өлкәсендә дә күп нәрсәдән хәбәрдар ул. Сәламәтлек буенча да аның янына бик еш киңәшергә керәбез. Хәер, Илсөярдән бер дигән инженер да чыгар иде. Нинди материалдан төзергә, кайсын күпме алырга – Илсөяр төгәллек белән бөтен сорауларга җавап бирә. Нияз белән икәүләп идән дә җәяләр, стена да өяләр. Өлгереп килә торган йортларын да икәү төзеделәр. «Бу һөнәргә мәхәббәт кайдан?» – дип сорыйм Илсөярдән.

– Бухгалтер һөнәрен дә бик яратам. Шул ук вакытта яңа һөнәр сайларга туры килсә, бәлки төзүче дә булыр идем. Бу кызыксыну миңа әнидән килә торгандыр. Әти без бала чакта гел ерак араларга командировкаларга йөри иде. Ул киткәч, әни белән ни дә булса үзгәртеп корырга, төзергә тотынабыз. Безгә ярдәмгә дәү әни дә килә. Әти кайтып төшә дә хәйран кала иде. Ни эшләсен, башлаганны тәмамлау аның үзенә кала. Ир-атлар эшне башлап җибәрергә авырсыныбрак торалар, холыклары шундый. Болай инде башлаган эшне бетерми мөмкин түгел. Бәлки, бу әнинең үзенә күрә бер хәйләсе дә булгандыр, – ди Илсөяр.

Илсөяр – Раил Садриевның авылдашы. Буага килүебезнең берсендә ул безне: «Ничек инде сез авылның иң хөрмәтле гаиләсе, Илфруз абый белән Альбира апаларга кермичә китәсез?» – дип, Илсөярнең әти-әнисе янына алып кергән иде. Була бит кояш кебек якты, җылы кешеләр. Бу гаилә дә нәкъ шундый. Оясында ни күрсә, очканында шул, диләр. Илсөярдәге сабырлыкның, төгәллекнең, тырышлыкның, җаваплылыкның каян килгәне аңлашыла.

Хезмәттәшебез Илсөярнең шушы көннәрдә – матур юбилее. Без аны чын күңелдән котлыйбыз. Исәнлек, иминлек, гаилә бөтенлеге телибез. Киләчәктә дә тормыш дисбесен чуалтмыйча, матур итеп яшәргә язсын.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

МАЛ БҮЛЕШӘ-БҮЛЕШӘ, БЕРТУГАННАР ҮЛЕШӘ

Суд залыннан

Лаеш районы судында озак еллар эшләүче Алсу Яруллина сүзләренә караганда, якын туганнар арасында мал-мөлкәт бүлешү, мирас мәсьәләсендә килеп чыккан үзара низаглар саны арта.

– Әти-әниләре мәрхүм булганнан соң, Казан читендәге җир кишәрлеген бүлешә алмыйча, озак вакытлар суд юлын таптаучылар да, фатир, машина кебек кыйммәтле әйберләрнең кемгә тиеш икәнен ачыклый алмыйча, дошманлашып беткән туганнар да аз түгел, – ди Алсу Яруллина.

Дошманлашу – бер хәл. Яшел Үзән районының Малые Ключи бистәсендә яшәүче бер ир-ат мираска тизрәк хуҗа булып алу ниятеннән әтисен явызларча кыйнап үтерә. Әзне югалту өчен үзенә гомер бүләк иткән, тәрбияләп үстергән кешенең гәүдәсен якындагы урманга алып барып яндыра.

Хәрам мал зыян китерә

Казахстанның Мамлютка шәһәрендә туып-үскән, соңгы елларда Лаеш районындагы Сокуры бистәсендә яшәүче Марат Шәфыйков, әти-әнисеннән калган ике катлы коттедж, өч бүлмәле фатир һәм башка мал-мөлкәтне абыйсы Самир белән бүлешмәс өчен, елдан артык дәвам иткән үзара ызгыш-талашларның берсендә кулына пычак ала. Тәртипле, җитеш гаиләдә яшәгән, югары белемле ир-атның үз туганына карата шундый адымга бара алуына әле дә ышанып булмый, ди Маратны белүчеләр. Куркыныч вакыйга Шәфыйковлар нәселен икегә бүлгән. Берәүләр озакка сузылган низагта Маратны гаепләсә, икенчеләр гаеп атта да, тәртәдә дә бар, димәкче.

Шәфыйковлар гаиләсеннән судта катнашучы бердәнбер кеше – Самирның тормыш иптәше әйтүенчә, бертуганнарның тормышларыннан һич кенә дә зарланырлык булмаган. Һәр икесенең Казан үзәгендә фатирлары, шәһәр читендә шәхси йортлары, чит ил машиналары, дистәләрчә миллион сумлык башка мал-мөлкәте бар. Ел саен дөньяның төрле илләренә сәяхәт кылу, гаиләләре белән иң яхшы ял йортларында сәламәтлекләрен ныгыту алар өчен гадәти хәл була.

– Әти-әни (урыннары җәннәттә булсын!) улларына яхшы тәрбия бирергә тырышты. Соңгы көннәренә кадәр кулдан килгәнчә безгә ярдәм итеп яшәделәр. Әни дини кеше иде. Әтиебезнең аракы белән сату итүен, алыпсатар булуына йөрәге әрнеде. Хәрам малның гаиләгә күңел тынычлыгы алып килүенә дә ышанмады, – ди мәрхүмнең тормыш иптәше Сәлимә ханым.

Хәрам дигәч тә, сүз ниндидер урлашу, талау кебек хәлләр турында бармый, билгеле. Җиңелрәк юл белән, аеруча хәмер сатып зур күләмдә керем алуга каршы була ике бала анасы. Әти-әнисе кылган гөнаһлар өчен балаларына җавап бирергә туры килүдән курка. Үзгәртеп кору шаукымы Казахстандагы башка милләт кешеләрен урыныннан кузгаткан еллар була ул. Татарстанда туып-үскән Гамир да туган якларына кайтып төпләнү турында хыяллана. Хатыны Сафураның уе да шулай – аеруча табиблар һава алыштырырга киңәш иткәннән соң, икесенең дә теләкләре бер була.

Бирәм дисә колына, чыгарып куя юлына дигәндәй, җае да килеп чыга. Татарстанда яшәүче бер гаилә Казандагы фатирларын алыштырырга теләп газетада игълан урнаштырган. Сөйләшә торгач, шактый күләмдә өстәмә акча түләп, ике гаилә уртак килешүгә ирешә.

Сәүдә техникумын тәмамлаган Гамир ага Казахстаннан күченеп кайтуга Казанның сәүдә базасына эшкә урнаша. Мамлютка районында кулланучылар җәмгыятендә директор урынбасары булып тәҗрибә туплауның файдасы тими калмагандыр. Бер елдан үз эшен башлап җибәрә.

– Ул еллар – бәяләрнең еллап түгел, көнләп үзгәргән чагы. Әтинең: «Вексельгә күпләп товар алып, башка төбәкләргә сатып, шактый акча эшлим», – дигәнен хәтерлим. Хуҗалыклар хезмәт хакы түләү өчен банк вексельләрен ярты бәясенә биргән чак. Бу – икеләтә файда китерә. Вексельгә товар алганда икеләтә файда кала. Өстәвенә сатканда үз процентларыңны кушасың. Әти чемодан тутырып, өйгә акча алып кайта иде, – дип искә ала Сәлимә ханым.

pixabay.com

Сәүдә эшенә бер-бер артлы Марат белән Самир да кушылып китә. Ике туган ярыша-ярыша акча эшли. Тик еллар гына үзгәреп китә. Гаиләгә бер-бер артлы кайгы килә. Баштарак озакка сузылган авырудан соң әниләре үлә. Берничә елдан юл фаҗигасендә әтиләре якты дөнья белән хушлаша. Канатсыз калган кошлар сыман, ике туганның да сәүдә эшләре кыенлашканнан-кыенлаша. Хәтта кибетләрен дә сатарга туры килә. Нәфесләре генә элеккечә кала.

– Булган саен күбрәк кирәк булды шул. Гөнаһлы кәсепнең нәселебез тамырына балта чабасын кем уйлаган? – дип өзгәләнә киленнәре.

Исән булса, бар малымны бирер идем

Ике туганның күгендә кара болытлар айлап түгел, көнләп куера. Соңгы елларда бар өметләре – әти-әниләреннән калган ике катлы коттедж, өч бүлмәле фатирны сату. Әмма булган мал-мөлкәтне гадел итеп бүлешәсе урында, кемгә күбрәк өлеш тияргә тиешлеге турында бәхәс, ызгыш-талаш елдан артык дәвам итә. Туганнар берсен-берсе күралмаслык хәлгә килеп җитә.

Фаҗига буласы көнне алар очраклы рәвештә гаражда очраша. Һәр икесе дә аны үзенеке санаганга, ачкычлар икесендә дә булган, күрәсең. Гөнаһ шомлыгына, Марат абыйсы белән очрашканчы гараж күршеләре белән шактый салып та алган. Судта: «Ничек итеп кулыма пычак алуымны хәтерләмим», – диюе дә шуңа бәйле булса кирәк.

Югыйсә Самир да энесенең нинди хәлдә булуын күргәндер. Тик әйтәсе сүзен әйтми калмаган. Гараж күршесе Рифкат Шәрипов сүзләренә караганда, беренче булып сугып җибәрүче дә ул була.

– Күкрәгендә кан күргәч, аптырап киттем. «Ашыгыч ярдәм» машинасы да тиз килеп җитте. Җәрәхәт йөрәк янына туры килгән, диделәр. Самир хастаханәгә барганда үлгән, – дип искә ала Рифкат Шәрипов.

Марат Шәфыйков кылган гамәле өчен барлык туганнарыннан гафу үтенде. Күз яшьләре аша берничә тапкыр: «Абый исән булса, барлык мал-мөлкәтемне аңа бирер идем», – диде. Тик ни хәл итәсең, терсәк якын да бит, тешләп булмый.

Тикшерү органнары вакыйгалар барышын энәсеннән җебенә кадәр ачыклаганнан соң, Марат Шәфыйков абыйсын үтерүдә гаепле дип табылды. Лаеш районы суды Марат Шәфыйковның беренче тапкыр җинаять кылуын, ике кечкенә баласы барлыгын, кылган гамәленә чын күңелдән үкенүен исәпкә алып, Россия Федерациясенең 105 маддәсе нигезендә каты режимлы колониядә тоту шарты белән 9 елга ирегеннән мәхрүм итү турында карар чыгарды.

Камил СӘГЪДӘТШИН

КОТЛЫЙБЫЗ!

Законнар иҗат итүдәге актив эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек комитеты әгъзасы **Галиев** Марат Һади улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлары өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Республика мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Социалистик Хезмәт Герое, Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Геройлары, Хәрби һәм Хезмәт Даны орденнары тулы кавалерларының Татарстан Республикасы иҗтимагый хәйрия оешмасы советы җаваплы секретаре **Фролов** Николай Васильевич **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Мәгълүмат технологияләрен һәм элемтә чараларын үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры **Хәйруллин** Айрат Ринат улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Россия телевидение һәм радиотапшырулар челтәре» федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Татарстан Республикасының радио-телевидение тапшыру үзәге» филиалы «Биләр» цехы авария-профилактика төркеменең радио һәм телевидение чаралары инженеры **Насыйбуллин** Әнәс Ясәви улына **«Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Машина төзү производствосының механикалаштырылган җыю эшләре слесаре **Айзатуллов** Илдар Туктарәки улына, электр энергиясе белән тәэмин итү үзәгенең насос җайланмалары машинисты **Гыйниязова** Ирина Анатольевнага, суыткыч приборлар һәм сәүдә-медицина җиһазлары җитештерүдә полиуретан нигезендә компаундлар әзерләү аппаратчысы **Иванов** Николай Валентиновичка, җиһазларны төзекләндерү үзәгенең тешле кискеч станок эшчесе **Сергеев** Александр Николаевичка **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Восток Зернопродукт» акционерлык җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Югары Ослан районы) **Андрианов** Николай Юрьевичка, «Козлова Мария Ивановна» крестьян (фермер) хуҗалыгы тракторчы-машинисты, механизаторы (Татарстан Республикасының Яңа Чишмә районы) **Барсуков** Михаил Федоровичка, «Битаман» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы (Татарстан Республикасы Биектау районы) **Гыймадиев** Тәлгать Нурмөхәммәт улына, «Нәҗәр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы (Татарстан Республикасының Әгерҗе районы) **Садыков** Рафил Мөдәррис улына, «Чистай» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Чистай районы) **Уваров** Виктор Михайловичка, «Урта Девятово» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Лаеш районы) **Ульянов** Александр Николаевичка, «Урал» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы механизаторы (Татарстан Республикасының Кукмара районы) **Фәлахов** Рәфкать Давыт улына, «Битаман» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы (Татарстан Республикасы Биектау районы) **Хөснетдинов** Камил Камай улына, «ОРСИС-АГРО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Яңа Афанас» терлекчелек комплексы терлекчелек тракторчысы (Татарстан Республикасының Түбән Кама районы) **Юнусов** Җәүдәт Нәҗип улына, «Борнак» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Якимов** Владимир Александровичка **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗӘК САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ КАРАР

8 декабрь, 2021 ел Казан ш. № 163/1388

2021 елның ноябрендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен раслау турында

Тиешле мәгълүматны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга бер календарь ае эчендә тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен билгеләү буенча Эш төркеменең «2021 елның ноябрендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләре турында» 6 декабрь, 2021 ел, № 95 карарын тикшергәннән соң, «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалы тарафыннан яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 11 ноябрь, 2010 ел, № 35/392 карары белән расланган Төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген бер календарь ае эчендә яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү тәртибенең VI бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе **карар бирә**:

1. 2021 елның ноябрендә төбәк телеканалы һәм радиоканалында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген яктыртуга тотылган эфир вакыты күләмен исәпләү нәтиҗәләрен (Эш төркеменең 6 декабрь, 2021 ел, № 95 карарында урын алган) расларга.

2. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ тарафыннан гамәлгә куелган һәм эшләтелә торган «Татарстан – Яңа Гасыр» телевидениесе» төбәк телеканалының 2021 елның ноябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген бер календарь ае эчендә тигез күләмдә яктырту турында «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәве турында бәяләмә чыгарырга.

3. «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖ тарафыннан гамәлгә куелган һәм эшләтелә торган «Татарстан – Яңа Гасыр» радиосы» – «Болгар» радиосы» радиопрограммасы» төбәк радиоканалының 2021 елның ноябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген бер календарь ае эчендә тигез күләмдә яктырту турында «Эшчәнлекләрен төбәк телеканалы һәм радиоканалында яктыртуда Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр тигезлеге гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәве турында бәяләмә чыгарырга.

4. Бу карарны «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» АҖгә, «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә, «Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе» сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлегенә җибәрергә.

5. Бу карарны бастырып чыгару өчен «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарына җибәрергә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

6. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе урынбасары О.В.Скворцяковка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе А.С.Кондратьев

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Секретаре Н.П. Борисова

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

«XXI ГАСЫР ЛИДЕРЫ» КАМИЛӘ ЮНЫСОВА:

«ПРЕЗИДЕНТ БЕЛӘН СӨЙЛӘШӘСЕМ КИЛӘ»

14 яшьтә үзишләреңне әйдәп бару авырмы? Бүген бездә кунакта – үрнәк күрсәтү, җаваплылык, үсеш, җәмәгать эшчәнлеге кебек сүзләр белән яхшы таныш булган, ил күләмендә уздырылучы «XXI гасыр лидеры» бәйгесендә Татарстан данын яклап, җиңү яулаган Камилә ЮНЫСОВА.

:: Камилә, лидерлык, җитәкчелек сыйфатларың кайдан килә дип уйлыйсың?

– Беренче чиратта, бу сыйфатлар әти-әниемнән күчкәндер. Сөйләүләре буенча, алар да төрле лагерьларга йөрергә яраткан, нинди генә чара булса да, читтә калмаганнар. Икенчедән, мондый сыйфатлар – үсеш, тырышлык нәтиҗәсе. Даими рәвештә мин төрледән-төрле бәйгеләрдә, форумнарда катнашам. Алар чын мәгънәсендә тагын да зуррак нәтиҗәләргә этәрә, үстерә.

:: Димәк, әти-әниең сине һәм синең эшчәнлекне яхшы аңлый?

– Әлбәттә! Алардан башка ирешкәннәремнең берсе дә булмас иде. Әти-әнием безнең оешмага һәм аның эшчәнлегенә хөрмәт белән карый. Күп кенә бәйгеләргә дә без бергәләп әзерләнәбез.

:: Син ил күләмендә уздырылучы «XXI гасыр лидеры» бәйгесенең җиңүчесе булдың. Бу турыда сөйлә әле.

– Әлеге бәйге эчендә «кайный» башлаганга тиздән бер ел була. «XXI гасыр лидеры»ның беренче этабы үзебезнең шәһәрдә булды. 16 гыйнвардан бирле әзерләндек без аңа. Мартта бу этапта җиңү яулавымны белдем һәм республика күләмендәге ярышка әзерләнә башладым. Анда исә III урынга лаек булдым. Алда ярымфинал иде. Ул быел онлайн форматта узды. Команда белән эшләү, кызыклы очрашулар, шәхси үсеш планын яклау – болары инде финалда булды. Татарстан данын дүрт кеше яклардык. Түземсезлек белән 7 декабрь – йомгаклау тантанасы көнен көттек. Җиңүче булуымны белгәч, әйтеп аңлата алмаслык хисләр кичердем. Тырышлык, үҗәтлек, шулкадәрле хезмәт юкка китмәде!

:: Бигрәк актив син! Буш вакытың каламы соң?

– Үз алдыма зур бурычлар куйсам да, ялга вакыт калдырырга тырышам. Көнне планлаштырганда, яхшылабрак уйласаң, барына да өлгереп була. Буш вакытымны гаиләм белән уздырырга яратам. Саф һавада йөрибез, төрле фильмнар карыйбыз, кунакка йөрибез. Шулай ук ял сәгатьләрен дусларым белән яки китап укып уздырырга яратам.

:: Киләчәктә кем булырга телисең?

– Әлегә төгәл генә әйтә алмыйм, ләкин минем кешеләр белән эшлисем килә. Алар белән бергә үсәргә телим.

:: Ә иң зур хыялың нинди?

– Хыялларым бик күп. Ләкин якын киләчәктә чынга ашырасы килгәннәре турында сөйләргә телим. Тиздән Республика Президентының Чыршы бәйрәме узачак. Минем бу бәйрәмдә Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов белән бергә утырасым һәм аралашасым килә. Ниятләрем турында сөйләр идем. Аннан соң, минем бик тә гаиләмне ял иттерәсем килә. Акча җыеп, бергәләп җылы якларга сәяхәткә чыгып китәргә телим. Һәм, әлбәттә, сәламәт һәм бәхетле булу – зур хыялларымның берсе.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

Кунагыбыз турында белешмә

- ✓ Камилә Чаллы шәһәренең А.С. Пушкин исемендәге 78 нче лицеенда 9 нчы сыйныфта белем ала.
- ✓ Республиканың талантлы балаларын берләштерүче «Совет детских организаций» оешмасының Чаллы филиалы лидеры.
- ✓ Камилә Чаллыда эшләп килүче «Круговорот» лагерендә әйдаман ярдәмчесе булып эшли.
- ✓ Ашарга пешерергә һәм елмаерга ярата.

Башыңны эшләт!



Безгә язалар

Әминә Җәләева, Казан шәһәренең Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназия укучысы

Азалия Садыйкова, Казан шәһәренең 143 нче мәктәбе укучысы

Шаян хикәя

«Мерседес» шәбрәк!

Фәнзиләне 713 нче номерлы балалар бакчасына тәрбияче итеп билгеләделәр. Кичә генә училище тәмамлап, бүген олы тормыш юлына аяк баскан кыз сөенеп туя алмады. Берсеннән-берсе сөйкемле сабыйларны күз алдына китереп, түземсезлек белән иртәгесе көнне көтте.

Менә ул бәләкәчләр!

Борын асты аллы-гөлле булып җемелдәгән берсенең башыннан сыйпады Фәнзилә:

– Әкият сөйлимме, балалар?

– Давай! – диде зур колаклы, тимгелле битле, муенына автомат аскан бер малай.

– Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер әби белән бабай, – дип сөйләп китте Фәнзилә. – Аларның балалары булмаган... Шуннан әби торкан да, камыр әвәләп, мичкә тыккан...

– Йомрыикмәк килеп чыккан мәллә?

Фәнзилә, аптырап, үзен бүлдергән ак бантиклы кызга карады. Ни өчендер ак бантиклы кызның колготкасы арт яктан таш тутырган төсле асылынып тора иде.

– Колобок турында сөйли, колобок! — дип шаулашты бәләкәчләр.

– Это мы знаем! – диде шулчак автомат аскан тимгелле битле малай. – Колобок соңыннан төлкегә закуска була. Давай бүтәнне!

– Ярар соң, – диде Фәнзилә, – тыңлагыз алайса. Диңгез буенда яшәгәннәр, ди, карт белән карчык. Көннәрдән бер көнне бабай алтын балык тоткан...

– Беләбез! – дип кычкырган тавышка сискәнеп китте Фәнзилә. Бая борын асты аллы-гөлле булып җемелдәгән җирән малай кычкырган икән. Җирән малай «голтырт» итеп борынын тартып куйды. Аллы-гөлле утлар юкка чыкты.

– Беләбез! – диде ул. – Балык аңа, җибәр, ди, бөтен нәрсәңне үтим, ди, и бабай ванна сорый.

– Ванна түгел, тагарак... – диде ак бантиклы кыз. Аның колготкасындагы таш идәнгә төшеп җитә язган иде.

– Да, тагарак. Аннан соң өй сорый, гараж.

– Гараж сорамый, – диде ак бантиклы кыз.

– Да, сорамый... Аннары бабай патша була.

– Бабай түгел, әби...

– Да, әби... – Җирән малайның борын асты тагын җемелди башлаган иде инде.

Фәнзиләнең түземлеге төкәнде:

– Нәрсә генә сөйлим соң сезгә? – диде ул, кулын як-якка җәеп. – Бөтен әкиятне беләсез икән ич инде?

pixabay.com

Шулчак автомат аскан малай алгарак чыкты:

– Апа, «Джип» шәбрәкме, «Мерседес»мы?

– Нәрсә, нәрсә? – Фәнзилә берни аңламый иде.

– «Джип» шәбрәк, – диде җирән малай. – Аның дүрт тәгәрмәче дә алга өстери.

– «Мерседес»та гел компьютер гына, – диде автомат аскан малай.

– Компьютер «Джип»та да бар...

– Аның каравы «Мерседес»та кондиционер...

– Ә «Джип»та климат-контроль...

Фәнзилә башы әйләнә башлавын сизде.

– Апа, мин «ә» иттем, – диде шулчак ак бантиклы кыз.

– Апа, сез кияүдәме?

– Апа, Ринат миңа өйләнәм, ди...

– Апа, Динал бүген тәмәке таллты...

– Апа, апа, Гүзәл әләкче ул...

Фәнзилә ак бантиклы кызны, колготкасын алыштырырга дип, бүтән бүлмәгә алып чыгып китте. Бу минутларда әле генә әкият тыңлаган балалар дөбер-шатыр котыра, автомат аскан малай «Мерседес»ның шәбрәк икәнен аңлата алмагач, җирән малайга автоматының түтәсе белән берне менеп төшәргә дә өлгергән иде инде.

Алмаз ГЫЙМАДИЕВ

Уйнап алабыз

Почмак алыш

Уенның максаты: балаларның сөйләм күнекмәләрен үстерү, аларда уяулык, җитезлек сыйфатлары тәрбияләү.

Балалар мәйданчыкның төрле урыннарында басып торалар. Алар – «әбиләр». Бер бала, «әбиләр» янына килеп, мунча сорап йөри:

– Әби, мунча бир әле?

– Мунчам буш түгел әле.

– Әби, мунча бир әле?

– Ташы төшкән.

– Әби, мунча бир әле?

– Мунча салырга агач юк. (Шулай итеп, төрле сәбәпләр әйтелә.)

Аннары тиз генә: «Һоп, һоп!» – дип, берничә мәртәбә кычкыралар. Шушы вакытта балалар урыннарын алыштыралар.

Мунча сораучы бала шушы арада берәрсенең урынын алып өлгерергә тиеш. Кем урынсыз кала, шул уенны дәвам итә.

Киңәш-табыш

БАЛАЛАР ӨЧЕН ФАЙДАЛЫ «ТИКТОК» КАНАЛЛАРЫ

Социаль челтәрләрне белем арттыру, хобби буларак та файдаланырга була. Моның өчен төрле каналлар ярдәмгә килә.

@Maths_with_july

Математика дигән авыр фәнне гади һәм аңлаешлы итеп аңлаталар бирелә.

@5.minute.crafts

Бу каналда көндәлек тормышта кулланырга мөмкин булган, тормышны җиңеләйтә торган киңәшләр тупланган.

@julia_novella

Педагог Юлия үзенең видеоязмаларында мәктәп программасына кертелгән әсәрләрнең кыскача эчтәлеген сөйли, танылган китаплардан фактлар китерә һәм аерым өлешләре турында фикер алышырга чакыра. Каналда – нигездә, рус әдәбияты әсәрләре.

@druzyashow

Санкт-Петербургтан ике әйдәп баручы химик белән физик кызыклы тәҗрибәләр күрсәтә һәм шулар турында сөйли.

Тест

ХОЛКЫҢ НИНДИ?

Кайчагында өлкәннәргә сабыйларның башында ниләр булганын, фикерләрен, карашларын аңлау җиңел түгел. Түбәндәге тестлар ярдәмендә ата-аналарга балаларының характерын ачыкларга тәкъдим итәбез.

ЗЕФИРЛЫ ТЕСТ. Балагыз стратегмы, тактикмы? Шушы тест сабыйдагы әнә шул сыйфатны ачыкларга ярдәм итәчәк.

Нәрсә кирәк булыр? Зефир (йә шоколад), өстәл, урындык, телевизор, телефон яисә игътибарны читкә юнәлтердәй башка предметлар булмаган буш бүлмә.

Нишләргә? Баланы өстәл янына утыртыгыз. Алдына тәм-том куегыз. Шарты мондый: әлеге тәм-томны ул бүлмәдә берүзе генә калган очракта ашый ала яисә, 10 минут көтсә, аны тагын да отышлырак тәкъдим көтә.

Стратег бала нишләр? Ул отышлырак тәкъдим өчен мизгеллек ләззәттән баш тартырга әзер. Тактик бала исә «монда һәм хәзер» дигән кагыйдәгә таянып эш итәчәк.

ИНТРОВЕРТМЫ, ЭКСТРАВЕРТМЫ?

Балагыз бик аралашучан, дөньядагы күренешләр белән кызыксына (экстраверт), әллә, киресенчә, үз эченә бикләнеп, үз хисләренә генә бирелә (интроверт) торганмы? Шушы тест ярдәмендә ата-аналар балаларындагы әлеге сыйфатны ачыклый ала.

Нәрсә кирәк булыр? Буялмаган рәсемнәр һәм төрле төстәге карандашлар.

Бала рәсемнәрне буяганда нәрсәгә игътибар итәргә? Иң элек, пөхтәлегенә, игътибарлылыгына. Әгәр дә бала рәсемнең чикләрен чыкмый, һәр өлешен матурлап, тырышып буйый икән, сезнең алда – интроверт.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7387 данә
Гомуми тираж – 17167 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 381

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+